ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/10

Яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезнамәләрне раслау һәм Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 маддәсенә, 2017 елның 22 декабрендә социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча Россия өчьяклы комиссиясе карары белән расланган (11 нче беркетмә) 2018 елга дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү системасын федераль, төбәк һәм җирле дәрәҗәдә билгеләү буенча бердәм тәкъдимнәргә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында» Карарына, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе 2 өлеше 52 пунктына нигезләнеп,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:

1) яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәне 1 нче кушымтада каралган тәртиптә;

2) яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләрнең гомуми тармак эшче һөнәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәне 2 нче кушымтада каралган тәртиптә

2. Әлеге Карарның 1 пункты белән билгеләнгән яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә билгеләнгән хезмәт хакы, җитәкчеләр һәм хезмәткәрләрнең хезмәт вазыйфалары күләме һәм квалификацияләре үзгәрешсез калган очракта, Карар нигезендә хезмәт хакы түләүгә кадәр гамәлдә булган хезмәт хакына түләү системасындагы түләүдән ким булмаска тиешлеген билгеләргә.

3. Шәһәр Советының 2018 елның 10 августында 26/9 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль китапханәләрендә, музейларында, музей тибындагы башка учреждениеләрдә һәм мәдәни – ял муниципаль учреждениеләрендә мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында Нигезнамәгә, 2 бүлекне 3 нче кушымтада каралган тәртиптә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

4. Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендә 24/7 санлы Карары белән расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләр кертәргә:

1) 11 пунктта «баланс комиссиясе беркетмәсе нигезендә Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.» сүзләрен «Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнә.» сүзләренә үзгәртергә;

2) «Вазыйфаи оклад күләме, сумнарда» баганасында «белгеч» юлында 21 пунктта «22 57» саннарын «12 057» саннарына алыштырырга;

3) 22.1 пунктын өстәргә:

«22.1. Әлеге Нигезнамәнең 22 пункты белән каралган учреждение җитәкчеләренә стимуллаштыру түләвенең конкрет күләме Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнә. »;

4) 22.2 пунктын өстәргә:

«22.2. Хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр хезмәт турындагы законнар һәм муниципаль хокукый актларга нигезләнеп билгеләнә.».

5. Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы «Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары һәм аерым муниципаль оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә

түләү шартлары турында» 26/8 санлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) муниципаль гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

– 25 пунктны түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча белән тулыландырырга:

«7) стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр»;

– түбәндәге эчтәлекле 56.17 пункты белән тулыландырырга :

«56.1. Хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр хезмәт турындагы законнар һәм муниципаль хокукый актларга нигезләнеп кабул ителгән локаль актлар белән билгеләнә.»;

– 86 пунктта «җитәкче урынбасарлары һәм баш хисапчылар» сүзләрен төшереп калдырырга;

– түбәндәге эчтәлекле 86.1. пунктын өстәргә:

«86.1. Җитәкчеләргәә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнә.»;

2) муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

– 17 пунктны түбәндәге эчтәлекле 8 пунктча белән тулыландырырга:

«8) стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр»;

– түбәндәге эчтәлектәге 55.1. пунктын өстәргә:

«55.1. Хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр хезмәт турындагы законнар һәм муниципаль хокукый актларга нигезләнеп кабул ителгән локаль актлар белән билгеләнә.»;

– 74 пунктта «Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы билгеләргә мөмкин» сүзләрен «Башкарма комитет билгели» сүзләренә алыштырырга;

– 76 пунктта «җитәкче урынбасарлары һәм баш хисапчылар» сүзләрен төшереп калдырырга;

– түбәндәге эчтәлекле 76.1. пунктын өстәргә:

«76.1. Җитәкчеләргәә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнә.»;

3) муниципаль өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

– 16 пункттагы 4-6 таблицаларны гамәлдән чыккан дип танырга;

– 34 пунктны түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча белән тулыландырырга:

«12) стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр»;

– түбәндәге эчтәлектәге 91.1. пунктын өстәргә:

«91.1. Хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр хезмәт турындагы законнар һәм муниципаль хокукый актларга нигезләнеп кабул ителгән локаль актлар белән билгеләнә.»;

– 116 пунктта «Муниципаль өстәмә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы билгеләргә мөмкин» сүзләрен «Башкарма комитет билгели» сүзләренә алыштырырга;

– 118 пунктта «муниципаль өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесе урынбасарлары, баш хисапчылары» сүзләрен төшереп калдырырга;

– түбәндәге эчтәлекле 118.1. пунктын өстәргә:

«118.1. Җитәкчеләргә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнә.»;

4) муниципаль белем бирү оешмаларында гомуми тармак эшче һөнәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификацион төркемнәре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

– 8 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр»;

– түбәндәге эчтәлектәге 20.1. пунктын өстәргә:

«91.1. Хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы башка түләүләр хезмәт турындагы законнар һәм муниципаль хокукый актларга нигезеләнеп кабул ителгән локаль актлар белән билгеләнә.»;

6. Әлеге Карар рәсми басылган көненән үз көченә керә, 1 пунктның үз көченә керү вакыты – 2018 елның 01 ноябре.

7. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме — Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ